ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.03.2021 376

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеге турында» 2019 елның 30 маендагы 877 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2008 елның 26 декабрендәге «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең мәгълүмати ачыклыгын тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеге турында» 2019 елның 30 маендагы 877 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген түбәндәге редакциядә 6 пункт белән тулыландырырга:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 | Муниципаль урман контроле | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль контроль бүлеге<br>ТР, Алабуга шәһәре, Тынычлык проспекты, 12, каб. 308, тел. (85557)3-69-48 | - РФ Җир кодексы;<br>- РФ Урман кодексы;<br>- «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2006 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон;<br>- «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм. муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда. юридик затларның һәм индивидуаль. эшкуарларның хокукларын яклау турында ". 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>- РТ Җир кодексы;<br>- РТ Урман кодексы;<br>- «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2017 елның 28 июлендәге 45 номерлы Татарстан Республикасы Законы;<br>- Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районы Уставын кабул итү турында» 2020 елның 29 июлендәге 491 номерлы карары;<br>-Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль контроль бүлеге турындагы нигезләмәне раслау турында» 2019 елның 12 мартындагы 347 номерлы карары;<br>-Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль контроль |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеге турында» 2019 елның 30 маендагы 877 номерлы карары;<br>- Алабуга муниципаль районы башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә муниципаль урман контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 2014 елның 2 сентябрендәге 964 номерлы карары. |

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов